# Гыйльметдин Идрисов

## Социалистик Хезмәт Герое



Кемерово өлкәсе Прокопьевск шәһәрендә шахтада эшли, соңрак бригадир була. Тырыш хезмәте өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнә, СССР Югары Советына ике чакырылышта депутат итеп сайлана.

Идрисов алтмышынчы еллар уртасында шахта күләмендә рекорд кую өчен ярышка чыга. 31 көн дигәндә, 302 метр проходка бирелә. Бу сан СССР министрлыгында Бөтенсоюз рекорды итеп теркәлә.

Ватаныбыз Идрисовның бу хезмәтен югары бәяли: аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирә.









# Фәймә Нигмәтҗанова

## СССР Дәүләт премиясе лауреаты



Халык куллануы товарлары цехында кассеталар җыючы булып эшли башлый. Нормасын алты йөз кассета урынына тугыз йөзгә җиткереп үти.

Шуңа Бөтенсоюз химиклар көнендә СССР Химия промышленносте министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. 1976 елда хезмәттәге уңышлары өчен Казан фотожелатин заводы премиясе лауреаты була. Хезмәттә ирешкән уңышлары өчен 1980 елда СССР Дәүләт премиясенә лаек була.



„Каждое утро десятки миллионов людей начинают свой очередной самый обыкновенный рабочий день...
Они, наверное, не думают о величии своих дел.
Но они, именно они, выполняя предначертания партии, поднимают Советскую страну к новым и новым высотам прогресса".

Л. И. БРЕЖНЕВ.

КОММУНИСТ 70-х

Опыт работы сборщицы кассет цеха товаров народного потребления Казанского фотожелатинового завода

НИГМАТЗЯНОВОЙ ФАЙМЫ ШАКИРОВНЫ



# Ринат Ибраһимов

## Вьетнам республикасында Татарстан илчесе



1990 елда, фәнни хезмәткәр буларак, Вьетнам Халык Республикасына аспирантурада укырга китә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына караган тышкы экономик элемтәләр бүлегенең көнбатыш илләре буенча җитәкче итеп билгеләнә.

2000 елның язында Вьетнам Республикасына Татарстан вәкиле итеп билгеләнә һәм хәзерге көндә шунда үзенең эш вазифаларын башкарырга җибәрелә.





# Гафият Гарифуллин



## РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре

Хезмәт юлын Кизел шәһәрендә бухгалтер булып башлый, 1957-1960 елларда-Яңа Сәрдектә председатель, 1960-1962 елларда берләштерелгән "Татарстан" колхозын җитәкли. 1962 елдан 1984 елга кадәр "Восток" хуҗалыгын җитәкли.

Сугыштагы батырлыклары өчен I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә.

Тырыш хезмәте өчен "РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре" исеменә лаек була. Шулай ук ике Хезмәт Кызыл Байрагы, "Почет билгесе", Октябрь революциясе орденнары һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнә.







# Галимулла Гарифуллин


## Татарстанның атказанган агрономы

Авыл хуҗалыгы техникумында агроном белгечлеге ала. 1956 елда "Электро" колхозында председатель ярдәмчесе булып эшли башлый. 1957 елдан -үзе хуҗалык рәисе була. 1960-1989 елларда «Россия» колхозын җитәкли.

Хезмәттәге тырышлыклары өчен "Татарстанның атказанган агрономы" исеменә, СССР Халык хуҗалыгы казанышлары (ВДНХ) күргәзмәсенең көмеш һәм бронза медальләре, Хезмәт Кызыл Байрагы, Ленин орденына лаек була.

# Илгизәр Ибраһимов

## "Мамадышнефтепродукт" АОҖ директоры



Хезмәт юлын "Россия" колхозында агроном булып башлый, "Восток" күмәк хуҗалыгында баш агроном булып эшли, күмәк хуҗалык рәисе итеп сайлана.

1988нче елда Мамадыш районына авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе итеп җибәрелә. 1991нче елда Мамадыш Район Советы рәисе һәм администрация башлыгы итеп сайлана. 1995 нче елдан ул –"Мамадышнефтепродукт" АО берләшмәсенең генераль директоры.

Илгизәр Рәфгат улы 1985нче елда "Почет билгесе" ордены белән бүләкләнә.







# Расих Гатауллин

## Ульяновск өлкәсе Закон чыгару җыелышы депутаты

Казан Дәүләт университетының физика факультетын тәмамлый, "Ульяновский Центр Микроэлектроники" НПК да фәнни хезмәткәр булып эшли. ТОО "Инфо-центр "Hard & Soft" директоры була. 1994 елдан “Мозаика” реклама төркеме баш редакторы һәм генераль директоры (ООО "Мозаика", Торговый Дом "Мозаика", Информационно-Рекламное Агентство "Мозаика") вазифасын башкара. Физика фәненә кагылышлы фәнни хезмәтләр авторы.


Расих Гатауллин: «Сильной партии нужна сильная оппозиция»





# Расим Шаһиев

## Татарстан Республикасы Атказанган тренеры

Милли көрәш буенча Россия чемпионы. «РСФСР Халык мәгарифе отличнигы» исеме, «Россия чемпионнары әзерләгән өчен» Россия Көрәш Федерациясе Дипломы, «Казанның 1000-еллыгына» медале, «ТР Мәгарифтәге казанышлары өчен» Күкрәк билгесе, «Милли көрәш буенча Татарстан Республикасының иң яхшы тренеры» Дипломы (3әү), «Татарстан Республикасы Атказанган тренеры» исеменә лаек була.










ФЕДЕРАЦИЯ ТАТАРО-БАШКИРСКОЙ НАЦИОНАЛЬНОЙ СПОРТИВНОЙ БОРЬБЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

СЕРТИФИКАТ

ТРЕНЕР ЧЕМПИОНА



# Айрат Абдуллин

## Техник фәннәр кандидаты

1982 елны КХТИ ның Түбән Камадагы Казан филиалына инженер итеп җибәрелә. 1985 елдан укытырга күчә. Шул ук елларда ”Югары температуралы энергетик корылмаларда радицион газ хәрәкәтләрен өйрәнү” дигән тема белән бәйле фәнни эш белән шөгыльләнә.

1990 елда елда Техник фәннәр кандидаты була. 1995 елда физика кафедрасы доценты дигән исем бирелә. 30 лап фәнни хезмәтләре бар.

# Шамил Хафизов

## Юридик фәннәр кандидаты



# Рифә Рахман

## Филология фәннәре кандидаты, шагыйрә

Казан Дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген, аспирантураны тәмамлый. Хәзерге көндә шунда белем бирә. 1996 елдан-Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 2008 елда С.Сөләйманова ис.емендәге бүләккә лаек була. Китаплары:



Шук алма, моңсу алма: шигырьләр. 1995.
Күзләрең төймәләнсә: шигырьләр. 1995.
Көзге төн күбәләге: шигырьләр. 1996.
Бармакларны уйнатыйк, туган телне өйрәник. 1997.
Төнге кояш. шигырьләр 1999.
Татар телендә 100 сочинение. 2001.
Керфекле тәрәзәләр: шигырьләр. 2002.
Коела йолдыз: шигырьләр. 2002.
Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. 2002.
Һәр сыйныфта — сочинение. 2003.
Болытка ятып йокласаң: шигырьләр. 2003.
Мине генә уйла: шигырьләр 2003.
Сиңа! 2003.
Дәреслектәге темалар һәм биремнәр буенча сочинениеләр. 2004.
Айлы күлдәвекләр: хикәяләр, кыйсса. 2006.
Югары сыйныфлар өчен иншалар һәм фәнни эш үрнәкләре. 2008.
Онытырмын, димә... 2010.



# Ирек Һадиев

## Татарстан Милли китапханәсе директор урынбасары

1988 елда Казан Дәүләт университетының тарих, татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Укыган чорда ук Казан Милли китапханәсенә эшкә чакырыла. Күп еллар китапханәнең сирәк кулъязмалар бүлеген җитәкли. Хәзерге вакытта-китапханәнең фәнни эшләр буенча директор урынбасары. Төбәкне өйрәнү буенча шактый эш башкара.
"Милли китап" нәшрияты директоры.
"Казанның 1000 еллыгы" медале белән бүләкләнә.

# Мәхмүт Исмәгыйлев




## Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы

КамАЗда эшләгәндә зур уңышларга ирешә, күп мәртәбәләр "Социалистик ярышта җиңүче" билгесе белән бүләкләнә.

90нчы елларда үзенең күңел кичерешләрен рәсемгә төшерә башлый. Казан шәһәрендә, Чаллыда, Кукмарада иҗат җимешләреннән күргәзмәләр оештырыла.

Аның рухи көче, омтылышлары, тормышка дәрте шигырьләрендә дә чагыла.
Хәзерге көндә аның тарафыннан 70 ләп шигырь иҗат ителгән, аларның күбесенә көйләр дә язылган.





## Җиһанша Мөбәрәкшин

### РСФСРның атказанган юристы



1946 елда сугыштан кайта һәм Казан юридик мәктәбенә укырга керә. Аны тәмамлагач, Әлмәт районында халык судьясы, 1952-1953 елда Чистай өлкә суды рәисе урынбасары булып эшли. 1953 елдан 30 елга якын Сабада хөкем сагында тора. Мәскәү Бөтенсоюз юридик институтын читтән торып тәмамлый.

Халык судьясының хезмәте гадел бәяләнә, РСФСР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә "РСФСРның атказанган юристы" дигән мактаулы исем республикада иң беренчеләрдән булып 1967 елда аңа бирелә. КПССның район комитеты составына даими сайлана, 20 ел буе суд һәм прокуратура каршындагы башлангыч партия оешмасы секретаре була. Сабадан китә һәм биш ел Әлмәт халык судында судья булып эшләгәч, ялга чыга.



## Наумир Сәмигуллин

### Ветеран-журналист, РСФСР ның халык мәгарифе отличнигы

Район һәм республика газеталарында, журналларда 100 дән артык публицистик мәкаләсе, очерк һәм зарисовкалары дөнья күргән. “Ил язмышы – ир язмышы” дигән әдәби тупланмасын чыгарды. Монда авторның тормышыннан вакыйгалар, авылдашларыбызның тыныч тормышта һәм сугыш кырындагы каһарманлыгы сурәтләнә.

Мәгариф өлкәсендәге 35 еллык хезмәте өчен РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы билгесе, министрлык грамотасы белән бүләкләнә. Ике тапкыр район Советы депутаты, республика Югары судына әгъза итеп сайлана.

Хәрби хезмәтләре өчен “гвардия” билгесе, “Батырлык өчен” медале, “Германияне җиңгән өчен” медале, 1 дәрәҗә Ватан сугышы орденына лаек була.

## Шәрифулла Нигмәтуллин

### ТАССРның атказанган экономисты, Мәскәүдә Кызыл мәйданда 5 парадта катнашкан ветеран



Бөек Ватан сугышы чорында һәм сугыштан соң Кызыл мәйданда Җиңү парадында һәм тагын 4 парадта катнаша. Сугыштан беткәч, 1949 елдан район Советының культура бүлеге мөдире булып эшли. 1952 елда өлкә партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, Яниль МТСында партбюро секретаре, КПСС райкомы секретаре хезмәтләрен башкара, КПСС райкомы аппаратында эшли. Район газетасында 10 ел редактор урынбасары, редактор вазифаларын башкара. СССР Журналистлар союзына кабул ителә.

1971 елдан 1985 елның мартына кадәр Кукмара район Советының план комиссиясе председателе, райбашкарма комитеты председателе урынбасары хезмәтен башкара. “ТАССРның атказанган экономисты” дигән исем бирелә.

1949-52 елларда район лекторлар группасы җитәкчесе, башлангыч партия оешмасы секретаре, 1965–71 елларда район профсоюз комитеты рәисе, 1971 елдан район тарихи һәйкәлләрне саклау оешмасы җаваплы секретаре була. 1985 елдан-Кукмара ветераннар советы рәисе, президиумы члены, республиканың районнардагы сугыш ветераннары белән эшләү буенча комиссия рәисе. РСФСР Мәдәният министрлыгы, республика хөкүмәтенең һәм профсоюз оешмалары, райком һәм исполком тарафыннан күпсанлы Мактау грамоталары һәм билгеләренә лаек була.

# Атказанган авылдашларыбыз



**Габделхәй Кадыйров**
Татарстанның атказанган механизаторы



**Зиннәтулла Зәкиуллин**
Татарстанның атказанган мал табибы



**Харис Ваһапов**
Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы



**Нурулла Шәрифуллин**
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре



**Рашит Габбасов**
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре



**Харис Хәлиуллин**
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре



**Нурзидә Шәрифуллина**
Татарстанның атказанган хисапчысы



**Нәҗия Галимуллина**
Татарстанның атказанган терлекчесе